**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары башкарма комитеты җитәкчеләре вазыйфаларын биләүгә кандидатураларны карау өчен конкурс комиссияләре әгъзалары исемлегенә үзгәреш кертү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 37 статьясындагы 5 кисәге нигезендә **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары башкарма комитеты җитәкчеләре вазыйфаларын биләүгә кандидатураларны карау өчен конкурс комиссияләре әгъзаларын билгеләп кую турында» 2014 елның 22 декабрендәге ПУ-1164 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2015 елның 17 сентябрендәге ПУ-874 номерлы Указы нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары башкарма комитеты җитәкчеләре вазыйфаларын биләүгә кандидатураларны карау өчен конкурс комиссияләре әгъзалары исемлегенә, 22 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

**«22. «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге:**

| | |
|---|---|
| Гарипов<br>Илнур Мәхмүт улы | Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесе урынбасары – Татарстан Республикасы Президентының Территорияләр белән эшләү идарәсе башлыгы |
| Егоров<br>Иван Михайлович | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты, «Ак Барс» холдинг компаниясе» ачык акционер җәмгыяте генераль директоры (килешү буенча) |

| | |
|---|---|
| Зарипов<br>Марат Рифгать улы | Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты рәисе |
| Камалтынов<br>Юрий Зимелевич | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе урынбасары (килешү буенча)». |

2. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан,Кремль
2015 ел, 20 октябрь
№ ПУ-999